Р. З. Хәйдәрова, Г. М. Әхмәтҗанова,
Л. Ә. Гыйниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ

## Укытучылар өчен методик кулланма

## 6



«Татармультфильм»

Р. З. Хәйдәрова, Г. М. Әхмәтҗанова,
Л. Ә. Гыйниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ

## 6 нчы сыйныф

**Укытучылар өчен методик кулланма**

*Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан тәкъдим ителгән*

Казан
2025

УДК 81.432.3-99(=411.2)я72
ББК 811.512.145(073.5)
Х18

Фәнни редакторы
**Р. З. Хәйдәрова**, педагогика фәннәре кандидаты, доцент

*Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всего издания или его части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*

**Хайдарова, Р. З. и др.**

Х18 Государственный (татарский) язык Республики Татарстан: Татар теле. 6 класс: методическое пособие для учителя к учебнику для общеобразовательных организаций основного общего образования (для обучающихся, не владеющих татарским языком) / Р. З. Хайдарова, Г. М. Ахметзянова, Л. А. Гиниятуллина. – Казань: Татармультфильм, 2025. – 40 с.

ISBN 978-5-906508-50-8

УДК 81.432.3-99(=411.2)я72
ББК 811.512.145(073.5)

ISBN 978-5-906508-50-8

© «Татармультфильм» нәшрияты, 2025
© Хәйдәрова Р. З., Әхмәтҗанова Г. М., Гыйниятуллина Л. Ә., 2025

## 6 нчы сыйныфта «Татарстан Республикасы дәүләт (татар) теле» фәнен укыту өчен төзелгән «Татар теле» укыту-методик комплекты белән эшләү үзенчәлекләре

Федераль дәүләт стандартларында белем бирү системасының төп үсеш юнәлеше – **системалы-эшчәнлекле юнәлеш (системно-деятельностный подход)**, ә системаны барлыкка китерә торган төп компонент – **нәтиҗә: шәхси, метапредмет, предмет нәтиҗәләре** дип билгеләнелә. Стандартларда күрсәтелгән бу концептуаль методологик күрсәтмә рус телле балаларга татар теле укыту системасын оештыруның да нигезе булып тора.

Рус телендә сөйләшүче укучыларга татар телен дәүләт теле буларак укытуның төп максаты – укучыларның рухи һәм әхлакый үсешен тәэмин итү, аларның күпмилләтле җәмгыятьтә милләтара культурасын формалаштыру, башка халыкларга карата хөрмәт хисе, мәдәниара диалогка осталык кебек универсаль күнекмәләр булдыру, татар телен дәүләт теле буларак укыту – телне **аралашу** чарасы буларак үзләштерүне тәэмин итү, көндәлек тормышта, полиэтник җәмгыятьтә **үзара аңлашу** һәм **хезмәттәшлек** итү күнекмәләрен формалаштыру. Шулай ук укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерү; уку эшчәнлеген оештыруның нигезе булган универсаль уку гамәлләрен формалаштыру, аларны мөстәкыйль уку эшчәнлегенә әзерләү.

Татарстан Республикасы мәктәпләре өчен төп гомуми белем бирү баскычында татар теле фәнен укытуга **372 сәгать** вакыт бирелә. Базис укыту планында 6 нчы сыйныфта атнага 3 сәгать исәбеннән **102 сәгать** каралган.

Алтынчы сыйныфта укучы рус телле балаларга тәкъдим ителгән укыту-методик комплекты (УМК) түбәндәге компонентлардан тора:

1. Дәреслек.
2. Укытучы өчен методик ярдәмлек:
   – календарь-тематик план;
   – ишетеп аңлау күнегүләре;
   – контроль-үлчәм материаллары.

УМКга эчтәлек сайлау Россия Мәгариф министрлыгының 18.05.2023 елгы 372 номерлы «Төп гомуми белем бирүнең федераль белем бирү программасын раслау турында»гы боерыгына (теркәлү вакыты: 12.07.2023 ел, № 74229) һәм тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына нигезләнде.

**Телгә аралашу аша өйрәтү принцибының** нигезендә дәреслеккә сайланган эчтәлекнең укучыларның яшь үзенчәлекләренә, теләк-омтылышларына, аралашу ихтыяҗларына туры килүе мәҗбүр. Шушы психологик, педагогик таләпләр үтәлгәндә генә уку материалын кабул итүдә укучыда актив фикри эшчәнлек башлана, үз фикерен әйтү теләге туа, укучы табигый рәвештә уку эшчәнлегенә тартыла. Ягъни укучыда укытучы кушканга түгел, ә үз теләге, үз ихтыяры белән табигый рәвештә сөйләм эшчәнлеге башлана.

Дәреслеккә түбәндәге аралашу темалары кертелде: «Яңа уку елы башлана» («Китап – белем чишмәсе», «Интернет дөньясында»), «Без – булышчылар», «Дуслар белән бергә», «Спорт, сәламәтлек, безнең шөгыльләр» («Түгәрәкләргә йөрү», «Ял итү төрләре»), «Туган җирем – Татарстан» («Татарстанда халыклар дуслыгы», «Казанның күренекле урыннары», «Экскурсияләр, походлар»). Тематик планнарда темаларның эчтәлеге киңәйтелеп, федераль эш программасына тәңгәллеге күрсәтелеп барылды.

Федераль эш программасына нигезләнеп, дәреслеккә грамматик материал түбәндәгечә кертелде:

– зат алмашлыкларының күплек сан иялек, юнәлеш килеше формалары *(безне – безгә, сезне – сезгә)*;

– *-лык/-лек, -даш (-дәш), -таш (-тәш)* (дуслык, сыйныфташ) исем ясагыч кушымчалары;

– парлы, кушма һәм тезмә исемнәр *(әти-әни, бала-чага, даруханә, җир җиләге)*;

– ясалма сыйфатлар: *-гы (-ге), -кы (-ке)* (җәйге, кышкы);

– билгеле һәм билгесез үткән заман хикәя фигыленең барлык һәм юклык формалары;

– билгеле һәм билгесез киләчәк заман хикәя фигыленең I, II, III зат берлек һәм күплек сандагы барлык, юклык формалары;

– боерык фигыленең II зат берлек һәм күплек сандагы барлык һәм юклык формалары *(бар! – барыгыз! – барма! – бармагыз!)*;

– «II зат боерык фигыль + әле кисәкчәсе» төзелмәсе (булыш әле, әйтегез әле);

– күләм-чама *(күп, аз)*, вакыт *(хәзер, башта, аннан соң)*, урын рәвешләре *(уңда, сулда)*;

– фигыльнең теләк белдерү формасы *(барасым килә (килми), уйныйсым килә (килми)*;

– шарт фигыльнең I, II, III зат берлек һәм күплек сандагы барлык, юклык формалары *(барса – бармаса, килсә – килмәсә)*;

– *әлбәттә, мәсәлән* кереш сүзләрен сөйләмдә куллану.

Күрсәтелгән эчтәлектән тыш, алдагы сыйныфларда өйрәнелгән лексик-грамматик материал даими рәвештә кабатланып барылды.

Рус телле балаларны татар сөйләменә коммуникатив технология нигезендә өйрәтү **дәреслекләренең төзелеше цикллылыкка** корылган. **Цикл – уку материалын диалогик, монологик, ягъни мөстәкыйль сөйләм дәрәҗәсенә җиткерү өчен кирәк булган дәресләр.** Ягъни өйрәнелгән лексик-грамматик материал, тану дәрәҗәсендә генә калмыйча, сөйләмдә мөстәкыйль кулланылу дәрәҗәсенә җиткерелергә тиеш. Дәрес тибы буенча бу дәресләр текст алды дәресләре: **лексик күнекмәләр формалаштыру** (ЛКФ) һәм **грамматик күнекмәләр формалаштыру** (ГКФ); текст өстендә эш дәресләре: **лексик, грамматик күнекмәләрне камилләштерү дәресләре** (ЛГКК), **диалогик/монологик сөйләм дәресләре** (Д/МС) дип атала. Бу дәресләр циклында өйрәнелгән лексика һәм грамматика турыдан-туры текстта кабатлана, төрле бәйләнешләргә керә, ягъни лингвистик материалны сөйләмдә куллану камилләшә. Тексттан соң булган этапта текст эчтәлеге буенча диалогик-монологик сөйләмгә чыгу дәресләре оештырыла, укучылар материал эчтәлеге буенча спонтан сөйләм – **татарча аралашу этабына** чыгалар.

Психологлар, методистлар фикеренчә, материалны кат-кат кабатлап, ятлап өйрәнүгә караганда, аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик-грамматик материалны укучыларның мөстәкыйль комбинацияләп сөйләшүе – тел өйрәнүдә күп мәртәбә нәтиҗәлерәк алым. Шуңа күрә дәреслектә эчтәлекне мөстәкыйль сөйләмгә җиткерү өчен сөйләми (речевые) күнегүләр: диалоглар, ситуатив күнегүләр, иҗади биремнәр еш кулланылды. Дәреслектәге күнегүләрдән тыш, укытучылар түбәндәге методик ярдәмлеккә мөрәҗәгать итә алалар: «Мин татарча сөйләшәм. Я говорю по-татарски». Сборник ситуативных упражнений для русскоязычных учащихся. Авт.: Р. З. Хайдарова, Г. М. Ахметзянова, Л. А. Гиниятуллина. Наб. Челны, 2019.

Телне аралашу ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, укучылар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен шундук тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм тел өйрәнү процессының мотивлашкан булуы тәэмин ителә.

Укучыларның сөйләми активлыгын булдыруда шулай ук уку эшчәнлеген оештыруның **эш режимнарын** дөрес оештыру да бик мөһим. Дәреслектә

**федераль дәүләт стандартларының таләпләренә туры килгән парларда, төркемнәрдә, индивидуаль эшләү өчен биремнәр һәм иҗади биремнәр киң урын алды**. Алар дәреслектә аерым шартлы билгеләр белән күрсәтелә бардылар.

Укытучы өчен **методик ярдәмлеккә** ишетеп аңлау күнегүләре (аудирование), федераль эш программасы нигезендә төзелгән календарь-тематик план, һәр тема буенча контроль, үзконтроль материаллары кертелде.

1) Ишетеп аңлау күнегүләре – һәр дәрестә, дәреснең төрле этапларында кулланылырга тиешле сөйләм эшчәнлеге. Ишетеп аңлау күнегүләренә таләпләр федераль эш программасында киң яктыртылу сәбәпле, методик ярдәмлектә дәрес темалары буенча күнегүләрнең үзләрен бирү белән чикләнелде.

2) Тәкъдим ителгән **тематик план** ел дәвамында өйрәнәсе материалның дәресләргә бүленешен күрсәтә. Һәр дәреснең коммуникатив максаты тематик планда аерым графада күрсәтелә барды, шуңа күрә дәрес планы, дәреснең структур этапларын планлаштырганда, аңа игътибар итү аеруча мөһим.

Федераль эш программасы бүлекләренең эчтәлеге тулысынча дәреслеккә һәм тематик планга салынды, аның үтәлеше күрсәтелә барды. Федераль эш программасы бүлекләренең эзлеклелеге белән дәреслектәге, тематик пландагы эчтәлек бирелеше эзлеклелеге тәңгәл килмәгән очракта да, **дәреслектәге һәм тематик пландагы дәресләр бирелешенең эзлеклелеген алыштырырга тәкъдим ителми**, чөнки федераль эш программасы нигезендә төзелгән дәреслек эчтәлегенең үзара бәйләнеше, системалылыгы бозыла.

3) Укыту процессының уңышлылыгына тәэсир итә торган әһәмиятле факторларның берсе – ул укучыларның белемен **контрольгә** алу. Билгеле булганча, **контроль** – укыту барышын көйли, ягъни, контрольгә карап, укытучы үз эшчәнлеген оештыра. Методика фәне билгеләгәнчә, укучыларның ятлаганны сөйли белүләре, аерым сүзләрне, җөмләләрне тәрҗемә итә белүләре яисә грамматик категорияләрне аңлый алулары гына **контроль объекты** була алмый. Контрольнең төп объекты булып, укучының өйрәнелгән лексиканы һәм грамматиканы кулланып, **мөстәкыйль аралаша алуы** тора. Календарь-тематик планның коммуникатив максат графасында дәресләр өчен күрсәтелгән **предмет нәтиҗәләре**, ягъни **тема буенча сөйләшә белү күләме** укучыларның белем дәрәҗәләрен контрольгә һәм үзконтрольгә алуның да эчтәлеге булып тора ала.

## Календарь-тематик план

| № | Дәрес темасы | Дәреснең коммуникатив максаты |
|---|---|---|
| **Яңа уку елы башлана (34 сәгать)**<br>**II. Мир вокруг меня** | | |
| 1–2 | Без мәктәпкә килдек.<br>Зат алмашлыкларының күплек сан иялек, юнәлеш килеше формалары (безнең – безгә, сезнең – сезгә) | 1 нче сентябрь бәйрәме белән дусларыңны, укытучыларны котлый белү. Бер-береңә комплиментлар әйтә белү. Уку-язу әсбаплары турында сөйләшә белү |
| 3–5 | 1 нче сентябрь бәйрәме.<br>Исемнәрнең тартым белән төрләнеше.<br>Тартымлы исемнәрнең сөйләмдә кулланылышы | 1 нче сентябрь бәйрәме турында сөйли белү. Уку-язу әсбапларының барлыгын, юклыгын, кирәклеген әйтә белү, үзең өчен сорый белү |
| 6–8 | Исемнәргә кушымчаларның ялгану тәртибе.<br>Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше.<br>Минем мәктәбем | Тартымлы исемнәрне сөйләмдә куллана белү. Дуслар белән бергә нәрсә эшләгәнеңне, нинди түгәрәкләргә йөргәнеңне әйтә белү. Текстны сәнгатьле уку, эчтәлеген сөйли белү |
| 9–10 | Сорау алмашлыклары.<br>Тартымлы исемнәрнең сөйләмдә кулланылышы | Сорау алмашлыкларын сөйләмдә урынлы куллану. Көндәлектәге билгеләр, китапханәдәге китаплар турында сөйләшү. |
| 11–12 | Транскрипция билгеләре.<br>Китап – минем дустым.<br>Без китаплар укыйбыз | Китапның ни өчен якын дус икәнлеген; нинди китап укыганыңны, нәрсә турында укыганыңны әйтә белү |
| 13–15 | Исемнәр ясалышы.<br>Кушма исемнәр.<br>Китап басу тарихы | Текстны сәнгатьле уку. Китап басу тарихы турында сөйли белү |
| 16–17 | Китапка ничә яшь?<br>Китап басу тарихы турында сөйләшәбез | Текстны сәнгатьле уку, эчтәлеген сөйли белү |
| 18–21 | Исем ясагыч кушымчалар.<br>Каюм Насыйри – зур галим.<br>Татар телендә сүзлекләр | Текстны сәнгатьле уку, эчтәлеген сөйли белү |
| 22–23 | Каюм Насыйри – бөек галим.<br>Каюм Насыйри турында сөйләшәбез | Каюм Насыйри эшчәнлеге турында сөйләшә белү |
| 24–25 | Бәйлекләр.<br>«Рәхмәт сиңа, китап!» тексты.<br>Яраткан китабым | Яраткан китабың, Интернет аша уку мөмкинлекләре турында диалог төзеп сөйләшү |

| | | |
|---|---|---|
| 26–28 | Интернет дөньясында | Интернетны ничек куллануың турында, аның уку, тормыш өчен файдалы һәм зарарлы якларын әйтә белү |
| 29–30 | Бәйлекләрнең сөйләмдә кулланылышы.<br>Без китапханәдә | Укылган китаплар, яраткан язучыларның китапларын алып уку турында диалоглар төзи, сөйләшә белү |
| 31 | Иялек килеше.<br>Иялек килешендәге исемнәрнең сөйләмдә кулланылышы | Исемнәрне иялек килешендә төрләндереп, сөйләмдә куллана белү |
| 32–34 | Хәзерге заман хикәя фигыленең юклык формасы.<br>«Ике дәфтәр сөйләшә» хикәясе.<br>Без хикәя язабыз | Текстны сәнгатьле уку, эчтәлеген сөйли белү.<br>Уку язу әсбапларына караш турында сөйләшү, яңа хикәя язу |
| **Без – булышчылар (15 сәгать)**<br>**I. Мир моего «Я»** | | |
| 35–36 | Без әнигә булышабыз.<br>Боерык фигыленең II зат берлек һәм күплек сандагы барлык һәм юклык формалары | Өйдәге эшләр, өлкәннәргә булышу турында сөйләшә белү |
| 37–39 | Шарт фигыленең зат-сан белән төрләнеше.<br>Шарт фигыленең сөйләмдә кулланылышы | Шарт фигыльне сөйләмдә куллана белү |
| 40 | *III зат берлек сан хәзерге заман хикәя фигыль + ала* төзелмәсе | *Юа ала* төзелмәсен аңлап куллана белү |
| 41–43 | «Супермалай» хикәясе.<br>Без хикәя сөйлибез | Текстны сәнгатьле уку, эчтәлеген сөйли белү.<br>Шарт фигыльле җөмләләр төзи белү |
| 44–46 | Фигыльнең теләк белдерү формалары: *барасым килә (килми), уйныйсым килә (килми); инфинитив + телим* төзелмәсе.<br>Кереш сүзләр.<br>Без хикәя язабыз | Теләк белдерү формалары: *барасым килә (килми), уйныйсым килә (килми); инфинитив + телим* төзелмәсен сөйләмдә куллана белү.<br>Текстны үзгәртеп яңа хикәя яза белү |
| 47–49 | Рәсим турында хикәя.<br>Р. Миңнуллин. «Әни кирәк».<br>Тезмә исемнәр | Текстны сәнгатьле уку, эчтәлеген сөйли белү, сәхнәләштерү.<br>Геройга бәя бирә белү.<br>Шигырьне яттан сөйләү |

| Дуслар белән бергә.. (21 сәгать)<br>I. Мир моего «Я» | | |
|---|---|---|
| 50–51 | Исемнәргә тартым һәм килеш кушымчаларының ялгану тәртибе.<br>Минем дустым | Үзеңнең дустың турында сөйли белү, диалоглар төзеп сөйләшә белү |
| 52–53 | Минем чын дустым.<br>Безнең дуслык | Чын дус нинди булуын әйтә белү. Дустың белән бергә нәрсәләр эшләү турында сөйләшә белү |
| 54–56 | «Дуслар дискотекада» хикәясе.<br>Без хикәя язабыз | Текстны сәнгатьле уку, эчтәлеген сөйли белү, сәхнәләштерү.<br>Яңа хикәя язу.<br>«Дуслык» темасына караган төрле ситуацияләрдә диалоглар төзеп, сөйләшә белү |
| 57–59 | «Сашаның дуслары» хикәясе.<br>Үтенеч һәм рөхсәт сорау формалары: *барыйм инде, барыйм әле* төзелмәләре.<br>Теләк белдерү формасы: *эчәсе килә* төзелмәсе | Текстны сәнгатьле уку, эчтәлеген сөйли белү.<br>*Барыйм әле, барыйм инде, эчәсе килә* төзелмәләрен сөйләмдә куллану |
| 60–61 | Билгеле киләчәк заман хикәя фигыль.<br>Билгеле киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше | Билгеле киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнешен тану, сөйләмдә куллану |
| 62–63 | Билгесез киләчәк заман хикәя фигыль.<br>Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше | Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнешен тану, аера белү |
| 64–65 | Рөхсәт сорау формалары.<br>II зат боерык фигыль + *әле кисәкчәсе* төзелмәсе *(бир әле, биреп торыгыз әле)*.<br>Рөхсәт сорау – кирәкле эш | Сөйләмдә рөхсәт сорау формаларын куллана белү |
| 66–67 | В. Осееваның «Зәңгәр яфраклар» хикәясе.<br>Без хикәя сөйлибез | Текстны сәнгатьле уку, эчтәлеген сөйли белү, сәхнәләштерү |
| 68–70 | Хикәя фигыльнең заман формалары.<br>Катя нинди дус?<br>Без хикәя язабыз | Катя образына бәя бирә, аңа киңәшләр бирә белү.<br>«Зәңгәр яфраклар» хикәясен үзгәртеп, яңа хикәя язу |

| | | |
|---|---|---|
| **Спорт, сәламәтлек, безнең шөгыльләр (15 сәгать)**<br>**III. Мир моих увлечений** | | |
| 71–73 | Җәйге, кышкы спорт төрләре.<br>Без спорт яратабыз.<br>Ясалма сыйфатлар: *-гы (-ге), -кы (-ке) (җәйге, кышкы).*<br>*Инфинитив + яратам (телим)* төзелмәсе | Нинди спорт төре белән шөгыльләнергә яратуыңны, нишли белүеңне (алуыңны), нинди спортчы булырга теләвеңне әйтә белү |
| 74–77 | Исем фигыль.<br>«Олимпия уеннары» тексты.<br>«Фигуралы шуу осталары» тексты | Текстны сәнгатьле уку, эчтәлеген сөйли белү.<br>Олимпия уеннарындагы спорт ярышларының төрләрен әйтә белү.<br>Татарстан спортчылары турындагы мәгълүматны сөйли белү |
| 78–80 | «Илдус һәм вирус» шигыре.<br>Еш авыруның сәбәпләре | Шигырьне сәнгатьле уку, эчтәлеген сөйли белү.<br>Авыруга киңәшләр бирә белү. Еш авыруның сәбәпләре турында сөйли белү |
| 81–82 | Тән әгъзалары.<br>Табибта | Кайсы җирең авыртуы турында сөйли белү |
| 83–85 | *Инфинитив (барлыкта һәм юклыкта) + кирәк* төзелмәсе.<br>Сәламәт булу өчен нишләргә кирәк? | Сәламәт булу өчен нәрсә эшләргә кирәклеген әйтә белү. Файдалы җиләк-җимешләр турында сөйли белү |
| **Туган җирем – Татарстан (17 сәгать)**<br>**IV. Моя Родина** | | |
| 86–87 | Туган җирем – Татарстан.<br>Россия – минем туган илем | *Ватан, ил, дәүләт, туган җир, халык, милләт, милли, башкала* төшенчәләрен аңлый, тәрҗемәсен белү. Шигырьне яттан сөйләү.<br>Россия һәм Татарстанның дәүләт символлары турында сөйли белү |
| 88–89 | Татарстанда яшәүче милләтләр.<br>Алынма сүзләр | Татарстанда яшәүче халыкларны, аларның туган телен әйтә, сорый белү |
| 90–91 | «Татарстан – дуслык иле».<br>Без нинди телләрдә сөйләшәбез? | Нинди телдә ничек сөйләшкәнеңне әйтә белү.<br>Сүзлекләрдән файдаланып,<br>«Кемнең теле бар, шуның иле бар» мәкале эчтәлеге буенча сөйләшә белү |

| | | |
|---|---|---|
| 92–93 | «Англиядән килгән кунаклар» тексты.<br>Без хикәя сөйлибез | Текст буенча сораулар төзи, *әлбәттә, мәсәлән* кереш сүзләрен кулланып, текстны сөйли белү |
| 94–95 | Урын, вакыт, охшату-чагыштыру рәвешләре.<br>Без хикәя язабыз | Рәвешләрне җөмләдә тану һәм сөйләмдә куллана белү. |
| 96–97 | Казан – Татарстанның башкаласы.<br>Казанның мәдәни үзәкләре | Казан Кремле турында сөйли белү.<br>Казандагы мәдәният үзәкләре турында диалоглар төзү |
| 98–102 | Татар халкының күренекле шагыйрьләре һәм язучылары | Күренекле язучылар һәм шагыйрьләр турында сөйли белү. Шигырьләрне сәнгатьле уку |

## ИШЕТЕП АҢЛАУ КҮНЕГҮЛӘРЕ

### Яңа уку елы башлана

### 1–2 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].**
котлыйм, уңышлар, билге, кирәргә, рөхсәтме, килешә

**2. Прослушайте и укажите слова со звуком [ө].**
сөйләшә, ошый, җыр, рөхсәт, бүген, дөрес, пөхтә, яңа

**3. Прослушайте и закончите предложения.**
1) Мин алтынчы сыйныфта ... .
2) Мин алты ел татар теле ... .
3) Мин татарча яхшы ... .
4) Миңа татарча җырлар, шигырьләр ... .

**4. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**
1) Син бүген матур. Син бүген бик матур.
2) Күлмәгең сиңа бик килешә. Костюмың сиңа бик килешә.

### 3–5 нче дәресләр

**1. Прослушайте и повторите слова, добавляя к каждому из них местоимение *минем*.**
шигырь, җыр, мәктәп, тасма, күлмәк, китап

**2. Прослушайте и укажите слова со звуками [қ], [к].**
китап, мәктәп, кул, чәй, кыз, якын, көн, котлый

**3. Назовите лишнее слово в логическом ряду.**
китап, дәфтәр, көндәлек, сөлге, каләм

**4. Прослушайте и повторите слова, добавляя к каждому из них местоимения *минем, синең, аның.***
китап, дус, мәктәп, карандаш

**5. Прослушайте предложения и составьте вопросы по образцу.**
Образец: *Синең дәфтәрең бармы?*
1) Минем дәфтәрем бар.
2) Минем төсле карандашларым бар.
3) Минем альбомым бар.
4) Минем китабым бар.
5) Минем плеерым бар.

## 6–10 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ө].**
китап, өстәл, дуслар, өй эше, мисал, чишә, йөри, пөхтә

**2. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нинди*?**
мәктәп, чиста, күп, кагыйдә, хата, кызыклы, пөхтә, зур, дәфтәр, китап

**3. Прослушайте начало предложений и закончите их.**
1) Мин мисал ... .
2) Мин кагыйдә ... .
3) Мин түгәрәккә ... .
4) Мин контроль эшкә ... .

**4. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**
1) Бу минем мәктәбем. Бу синең мәктәбең.
2) Мин математика түгәрәгенә йөрим. Мин татар теле түгәрәгенә йөрим.
3) Синең язма эшеңдә хата бар. Синең өй эшеңдә хата бар.

## 11–12 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].**
сердәш, дус, киңәшчем, китап, дәфтәр, иптәш, сәнгать

**2. Прослушайте и укажите лишнее слово в логическом ряду.**
мин, син, алар, апа, ул, без, сез

**3. Прослушайте и повторите слова, добавляя к каждому из них местоимения *минем, синең, аның.***
китап, апа, дус, исем

**4. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Китап миңа төрле киңәшләр бирә. Китап безгә төрле киңәшләр бирә.

2) Китап төрле һөнәрләр турында мәгълүмат бирә. Китап төрле фәннәр турында мәгълүмат бирә.

**5. Прослушайте начало предложения и закончите их.**

1) Китап – минем якын ... .
2) Китап – минем яхшы ... .
3) Китап – минем зур ... .

**6. Прослушайте и измените предложения по образцу.**

О б р а з е ц : *Дәфтәр. – Айдарның дәфтәрендә.*

дәфтәр, китап, пенал, портфель, альбом, дәреслек

## 13–17 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [h].**

шәһәр, балчык, таяк, тамга, һәйкәл, кульъязма, китапханә, хәзер, әкият

**2. Прослушайте и укажите слова со звуком [ķ].**

балчык, таяк, тамга, китап, кульъязма, һәйкәл, китапханәләр, таш

**3. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *ничәнче*?**

бер, ике, өченче, дүрт, бишенче, алтынчы, җиде, сигезенче, тугызынчы, ун

**4. Прослушайте начало предложений и закончите их.**

1) Китапларны башта балчыктан ... .
2) Таяклар белән тамгалар ... .
3) Беренче рус китап басучысының исеме – ... .
4) Татарстанда иң зур китапханә – ... .

**5. Прослушайте и скажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Китапларга берничә мең яшь. Китапларга хәзер берничә мең яшь.

2) Китапларны балчыктан ясаганнар. Китапларны башта балчыктан ясаганнар.

3) Кытайда китапларны бамбук пластинкаларга язганнар. Кытайда беренче китапларны бамбук пластинкаларга язганнар.

## 18–23 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ч].**
тарих, бакча, галим, телче, русча, сүзлек, кичә, укытучы

**2. Прослушайте и укажите слова, состоящие из двух слогов.**
белем, халык, табигать, дәреслек, фән, балалар

**3. Прослушайте и укажите лишнее слово в логическом ряду.**
тәрбияче, эшче, бакчачы, укытучы, тәрҗемәче, тарих, телче, урманчы

**4. Прослушайте и скажите, что пропущено во втором предложении каждой пары.**

1) Каюм Насыйри – тарихчы, тәрҗемәче, телче, галим.
Каюм Насыйри – тарихчы, телче, галим.

2) Каюм Насыйри татар теленең аңлатмалы сүзлеген, русча-татарча, татарча-русча сүзлекләр бастыра.
Каюм Насыйри татар теленең аңлатмалы сүзлеген, татарча-русча сүзлекләр бастыра.

3) Каюм Насыйри математика, география, табигать фәннәре буенча терминнар сүзлеге төзи.
Каюм Насыйри математика, география фәннәре буенча терминнар сүзлеге төзи.

## 24–31 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нишли*?**
языла, килә, маҗаралы, бара, китап, сорый, ясый, укырга.

**2. Прослушайте и назовите вопросительные предложения.**

1) Мин китапханәгә барам.
2) Керергә рөхсәтме?
3) Мин алтынчы сыйныфта укыйм.
4) Китапханәгә язылырга мөмкинме?
5) Китапны саклап тотарга кирәк.
6) Син нинди китаплар укырга яратасың?

**3. Прослушайте и измените слова по образцу.**

О б р а з е ц : *китапханә – китапханәгә*

| | |
|---|---|
| сыйныф – | фатир – |
| урам – | кунак – |
| йорт – | дәрес – |

**4. Назовите лишнее слово в логическом ряду.**

кемгә, нинди, ничә, шигырь, ничәнче, нишли

**5. Прослушайте и измените слова по образцу.**

О б р а з е ц : *Айдар, дәфтәр – Айдарның дәфтәре.*

Саша, китап; апа, сумка; Коля, ручка; Ринат, җавап; малай, туп.

**6. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Безнең мәктәптә китапханә бар. Безнең мәктәптә зур китапханә бар.
2) Мин китап укырга яратам. Мин мавҗаралы китап укырга яратам.
3) Китапханәгә китаплар кайтты. Китапханәгә яңа китаплар кайтты.

**7. Продолжи советы.**

1) Китапны ... .
2) Китапка майлы ... .
3) Китапны бөкләргә ... .
4) Китапны чиста кул ... .

**8. Прослушайте и скажите, с какими утверждениями вы не согласны.**

1) Интернетта бөтен дөньядан мәгълүмат тупланган.
2) Интернетта язучыларның әсәрләрен, музыка табып булмый.

3) Интернетта информация һәрвакыт дөрес.
4) Интернет вирусларга бай.
5) Интернет сәламәтлек өчен зыянлы.
6) Интернетта китаплар укып була.
7) Интернет – иң кирәкле информация чыганагы.
8) Интернет укуда һәрвакыт булыша.

## 32–34 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [җ].**

җәй, дәфтәр, хуҗа, билге, күз, чирек, җөмлә

**2. Прослушайте и укажите слова с мягким произношением.**

бервакыт, дәфтәр, билге, әйбәт, уңайсыз, күз, бит, хуҗа

**3. Расположите эти числа по порядку.**

беренче, өченче, унынчы, бишенче, дүртенче, икенче, алтынчы, тугызынчы, җиденче, сигезенче

**4. Измените слова по образцу:**

Образец: укый – укымый

очраша, исәнләшә, сөйли, ярата, саклап тота, аңлата, ала, ыргыта, ерта.

**5. Прослушайте и укажите предложения, в которых есть слова, отвечающие на вопрос *нинди?***

1) Мин бик яхшы укыйм.
2) Минем дәфтәремдә яхшы билгеләр генә бар.
3) Минем дәфтәрем чиста, пөхтә.
4) Ул тиз укый.
5) Ул әйбәт хуҗа.

**6. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Китапны саклап тот. Син китапны саклап тотасыңмы?
2) Оля китапханәдән китап алсын. Оля мәктәптән китап алсын.
3) Син мисалны үзең чиш. Син мисалны үзең чиштеңме?

## Без – булышчылар

### 35–36 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].**
җыештыра, булыша

**2. Измените слова по образцу.**
О б р а з е ц : *Син ю! Син юма!*
себерә, юа, җыештыра, булыша

**3. Прослушайте диалог и перескажите содержание своими словами.**
– Айдар, син әти-әниеңә булышасыңмы?
– Әйе, мин һәрвакыт аларга булышам.
– Әниеңә нәрсәләр эшләргә булышасың?
– Әниемә өйдә булышам: тузан суыртам, чүп чыгарам.
– Ә әтиеңә булышасыңмы?
– Әйе, әтиемә җир казырга, утын кисәргә булышам.

**4. Прослушайте и закончите предложения.**
1) Гүзәл әнисенә кер юарга ... .
2) Оля әбисенә аш пешерергә ... .
3) Денис әтисенә утын кисәргә ... .
4) Ләйсән Лилиягә мәсьәлә чишәргә ... .

**5. Прослушайте текст и придумайте к нему начало.**

Гүзәлнең әбисе бик шат булды. «Кызым, сиңа бик зур рәхмәт, эшләвең минем өчен булса, өйрәнүең үзең өчен», – диде.

### 37–39 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите глаголы условного наклонения.**
себерә, булышса, юа, җыештыра, әйтсә, булыша, булышмаса, йоклый

**2. Прослушайте и повторите данные глаголы в условном наклонении.**
булыша, себерә, эчә, килә, бара, эшли, утыра

**3. Прослушайте и скажите, что добавлено ко второму предложению каждой пары.**

1) Яз җитә, көннәр җылына. Яз җитсә, көннәр җылына.

2) Җәй җитә, каникуллар башлана. Җәй җитсә, каникуллар башлана.

3) Көннәр җылыта. Кояш чыкса, көннәр җылыта.

4) Мин яхшы билгеләр алам. Өй эшен эшләсәм, мин яхшы билгеләр алам.

**4. Прослушайте и повторите слова, добавляя к каждому из них подходящие местоимения *мин, син, ул*.**

булышса, себерсәң, эчсәм, килсәң, барсам, эшләсә, утырсаң

## 40–46 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [қ].**

кар, кибет, көри, урындык, төзәтә, алып кайта, кисә

**2. Прослушайте и укажите количество слогов в словах.**

утын, урман, маҗаралы, китап, урындык, себерә, тәрбияле, салкын

**3. Прослушайте и скажите данные слова во множественном числе.**

супермалай, кибет, ипи-сөт, чишмә, су, кар, утын, китап, урындык, идән

**4. Прослушайте и скажите, как изменились бы эти глаголы, если бы действия не происходили.**

көри, төзәтә, алып кайта, кисә, себерә, эшли

**5. Прослушайте и закончите предложения.**

1) Супермалай кибеттән ипи, сөт алып кайтырга тели, ләкин ... .

2) Супермалай утын кисәргә тели, ул ... .

3) Ул эшләргә тели, ләкин ... .

4) Ул су алып кайтырга тели, ләкин ... .

## 47–49 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и скажите, как изменятся эти глаголы, если действия уже произошли.**

әзерли, уйный, эшли, бирә, булыша, килә, әйтә, чишә, әрчи, тыңлый, юа

**2. Прослушайте слова и измените их по образцу.**
О б р а з е ц : әзерли – әзерләргә кирәк
эшли, булыша, әйтә, әрчи, тыңлый, юа

**3. Прослушайте и скажите, что добавлено ко второму предложению каждой пары.**
1) Әни аш әзерли. Әни иртәнге аш әзерли.
2) Мин мәктәптә аш ашыйм. Мин мәктәптә көндезге аш ашыйм.
3) Без аш өстәле әзерләдек. Без кичке аш өстәле әзерләдек.

**Дуслар белән күңелле**

**50–53 нче дәресләр**

**1. Прочитайте и укажите двусложные слова.**
дус, дустым, дусларым, күп, дуслар, мин, без, дусларга, дуска

**2. Прочитайте и скажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**
1) Мин дустыма котлау яздым. Мин дустыма хат яздым.
2) Мин дустымны кунакка чакырдым. Мин дустымны бәйрәмгә чакырдым.
3) Дустымның дуслары бик күп. Дустымның танышлары бик күп.
4) Без авылда дуслаштык. Без шәһәрдә дуслаштык.

**3. Прочитайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *кая?***
1) Без дустым белән Казанга барабыз.
2) Казанда безнең туганнар бар.
3) Казанда театрга, музейга барабыз.

**4. Прослушайте диалог. Что вы узнали об Алсу?**
– Галя, син Алсуны беләсеңме?
– Әйе, без дуслар.
– Ул кайсы мәктәптә укый?
– 15 нче мәктәптә.
– Ничәнче сыйныфта?
– Ул алтынчы сыйныфта укый.

**5. Прочитайте предложения, скажите, что изменено в каждом последующем предложении.**

А. 1) Без таныштык.
   2) Без кунакта таныштык.
   3) Без Казанда кунакта таныштык.
   4) Без быел Казанда кунакта таныштык.
   5) Без дустым белән быел Казанда кунакта таныштык.

Б. 1) Дус ярдәм итә.
   2) Чын дус ярдәм итә.
   3) Чын дус һәрвакыт ярдәм итә.

**6. Прослушайте и скажите, как относится Оля к Лейсан.**

1) Минем исемем Ләйсән.
2) Минем Оля исемле дустым бар.
3) Мин аны бик яратам.
4) Ул миңа булыша, минем белән бергә уйный, миңа ышана, алдашмый.

### 54–59 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите двусложные слова.**

дискотека, син, әйдә, бергә, барабыз, яхшы, бәйрәмдә, иптәш, йөгерде, кыен, булды

**2. Прослушайте и закончите предложения.**

А. 1) Без бүген дискотекага ... .
   2) Без бүген дискотекадан ... .
   3) Без дискотекада ... .

Б. 1) Мин бәйрәмгә ... .
   2) Мин бәйрәмдә ... .
   3) Мин бәйрәмнән ... .

**3. Прочитайте и скажите, которое из двух предложений подходит к содержанию текста.**

1) Наилә дискотекага берүзе барды. Наилә дискотекага Лена белән барды.

2) Лена бәйрәмдә Алсу янына бармады. Лена бәйрәмдә Алсу янына китте.

3) Лена дискотекада минем белән биеде. Лена дискотекада Алсу белән биеде.

4) Мин дискотекада берүзем биедем. Мин дискотекада Лена белән биедем.

**4. Прослушайте и скажите, с какими утверждениями вы согласны.**

– Лена дөрес эшләде, чөнки ул Алсу белән дус.

– Лена дөрес эшләмәде, чөнки Наилә берүзе калды.

– Лена дөрес эшләде, чөнки Наилә Лена белән дус түгел.

– Лена дөрес эшләмәде, чөнки ул Наиләне дискотекага үзе чакырды.

**5. Прослушайте и закончите рассказ.**

Илнур, Руслан, Камил – дуслар. Русланның әнисе өйдә юк. Аларга тиздән кунаклар килә. Өйдә эш бик күп. Ул дусларына шалтыратты. ...

**6. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Минем урамга чыгасым килә. Минем хәзер урамга чыгасым килә.

2) Минем сок эчәсем килә. Минем су эчәсем килә.

3) Азатның маҗаралы китап укыйсы килә. Азатның кызыклы китап укыйсы килә.

4) Минем кич йоклыйсым килә. Минем иртән йоклыйсым килә.

## 60–63 нче дәресләр

**1. Прослушайте и выберите глаголы будущего определённого времени.**

йөри, барачак, китә, язачак, уйлый, әйтәчәк, әзерли, җыячак

**2. Прослушайте и измените слова по образцу.**

Образец: *уйнады – уйнаячак.*

авырды, әзерләде, бирде, күрде, сорады, җыйды, чакырды

**3. Прослушайте и выберите глаголы будущего неопределённого времени.**

йөрер, барачак, китәр, язар, уйлый, әзерләр, җыячак

**4. Прослушайте и укажите количество слогов в данных словах.**
дуслар, икәү, мәктәпкә, түгәрәккә, китапханәгә, уйный, дәрес, әзерли

**5. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**
1) Мин кинога барам. Мин кинога барачакмын.
2) Мин кибеткә барам. Ярый, мин кибеткә барырмын.
3) Син дискотекага барасың. Син дискотекага барачаксың.

**6. Прослушайте текст и перескажите.**
Оля, Алсу, Лена – дуслар. Алар мәктәпкә, бию түгәрәгенә, китапханәгә бергә йөриләр. Алар бүген бергә дәрес әзерләячәкләр.

## 64–70 нче дәресләр

**1. Прослушайте слова и измените по образцу.**
Образец: *бир – бир әле*
булыш, әзерлә, чакыр, чык, кайт, эзлә

**2. Прочитайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них местоимения *минем, синең, аның*.**
карандаш, абый, әни

**3. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**
1) Катяның яшел карандашы бар. Катяның ике яшел карандашы бар.
2) Миңа карандаш биреп тор әле. Миңа яшел карандаш биреп тор әле.
3) Мин рөхсәт сорармын. Мин әниемнән рөхсәт сорармын.
4) Әнисе барырга кушты. Әнисе кибеткә барырга кушты.

**4. Прослушайте и скажите, с какими утверждениями вы согласны.**
– Катя дөрес эшләде, чөнки аның карандашы бозыла.
– Катя дөрес эшләмәде, чөнки Ленаның яшел карандашы юк.
– Катя дөрес эшләде, чөнки Катя әнисеннән рөхсәт сорарга теләде.
– Катя дөрес эшләмәде, чөнки Лена – аның дусты.

**5. Прослушайте и закончите рассказ.**

Катяның ике яшел карандашы бар, ә Ленаның яшел карандашы юк. Лена Катядан яшел карандаш сорады. ...

## Спорт, сәламәтлек, безнең шөгыльләр

### 71–79 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите лишнее слово в логическом ряду.**

чаңгы шуу, бадминтон, теннис, волейбол, йөзү, футбол, кегли

**2. Прослушайте начало предложений и закончите их.**

1) Мин хоккей яратам, хоккейчы булырга ... .
2) Мин йөзәргә яратам, йөзүче булырга ... .
3) Син көрәш яратасың, сиңа көрәшче булырга ... .

**3. Прослушайте диалог и перескажите его содержание своими словами.**

– Олег, син спорт түгәрәгенә йөрисеңме?

– Юк. Ә син, Марат?

– Әйе, мин футбол түгәрәгенә йөрим, чаңгы шуарга йөрим. Ә син, Олег, чаңгы шуарга яратасыңмы?

– Яратам, ләкин бик сирәк шуам.

**4. Прослушайте диалог и перескажите его содержание.**

– Олимпия уеннары кайда барлыкка килгән?

– Олимпия уеннары Борынгы Грециядә барлыкка килгән.

– Олимпия уеннарында нинди төр ярышлар була?

– Йөгерү, сикерү, велосипед, футбол, баскетбол, дзюдо ярышлары, яхта һәм каноэда узышу һәм башка ярышлар була.

### 80–85 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].**

сәламәт, салкын, йөзә, уйный, сикерә, шуа, гадәт

**2. Прослушайте и измените слова по образцу.**

Образец: *авырый – авырмый.*

салкын тия, чыныга, йоклый, йөгерә, йөри, уяна, саклый

**3. Прослушайте и укажите слова со звуком [қ].**

күрше, салкын, дус, тамак, каршында, суык, чыныга

**4. Прослушайте и скажите, как изменились бы эти глаголы, если бы действия не происходили.**

авырый, авырта, уйный, урамга чыга, суык тия, өстенә кия

**5. Прослушайте диалоги, вставьте пропущенные реплики.**

– ...?

– Спорт белән шөгыльләнгән кеше сәламәт була.

– ...?

– Ярый, иртәгә бергә чаңгы шуарга барабыз.

**6. Прослушайте диалог и перескажите его содержание.**

– Андрей, син бер дә грипп белән авырмыйсың. Моның сере нәрсәдә?

– Мин иртән зарядка ясыйм, салкын су белән юынам. Кич телевизор күп карамыйм. Дәресләрне әзерләгәч, саф һавада йөрим.

## Туган җирем – Татарстан

### 86–89 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [и].**

Ватан, ил, дәүләт, туган җир, халык, милләт, милли, башкала

**2. Прочитайте и скажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Татарстан – бай дәүләт. Татарстан – зур дәүләт.

2) Татарстанның үз флагы бар. Татарстанның үз гербы бар.

3) Татарстан флагында өч төс бар. Татарстан флагында өч төс бар: яшел, ак, кызыл.

**3. Прослушайте диалог и перескажите его содержание.**
– Саша, Татарстанның нинди милли символлары бар?
– Татарстанның үз флагы, үз гербы, үз гимны бар.
– Гербка нәрсә ясалган?
– Ак барс рәсеме ясалган.

**90–91 нче дәресләр**

**1. Прослушайте и укажите слова с твёрдым произношением.**
дәүләт, тел, рус, русча, милләт, татар, татарча

**2. Прослушайте и закончите предложения.**
1) Безгә Башкортстаннан кунаклар ... .
2) Без башкортча җырлар ... .
3) Мин – рус, минем туган телем – ... .
4) Мин – рус, ләкин татар җырларын ... .

**3. Прослушайте и скажите, с какими утверждениями вы согласны.**
– Чит телне яхшы белсәк, безгә җитә.
– Рус телен яхшы белсәк, безгә җитә.
– Рус телен, татар телен яхшы белергә кирәк.
– Рус телен, татар телен, чит телләрне яхшы белергә кирәк.

**4. Прослушайте и скажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Татарстанда татарлар, руслар дус-тату яшиләр. Татарстанда татарлар, руслар һәм башка халыклар дус-тату яшиләр.

2) Без милли җырлар өйрәнәбез. Без милли җырлар, милли биюләр өйрәнәбез.

3) Һәр кеше үз ана телен белергә тиеш. Һәр кеше үз ана телен белергә, хөрмәт итәргә тиеш.

**5. Прослушайте и составьте диалог по вопросам.**
1) Сезнең сыйныфта нинди милләт балалары укый?
2) Син нинди телләрдә сөйләшә беләсең?
3) Татарстанда ничә дәүләт теле бар? Алар нинди телләр?

## 92–95 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите двусложные слова.**
кунак, җырчы, язучылар, тамаша, атна, кызганыч, инглиз теле

**2. Прослушайте и закончите предложения.**
1) Безгә Англиядән кунаклар ... .
2) Без инглизчә җырлар ... .
3) Атна буе мәктәптә инглиз теле ... .
4) Без татар җырларын ... .

**3. Прочитайте и скажите, которое из двух предложений подходит к содержанию текста.**

1) Мәктәпкә Англиядән кунаклар килде. Мәктәпкә Германиядән кунаклар килде.

2) Без инглизчә җырлар җырладык, шигырьләр сөйләдек. Без татарча җырлар җырладык, шигырьләр сөйләдек.

3) Без татар җырларын яхшы беләидек. Без татар җырларын начар белә идек.

**4. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос нинди?**
чыгыш ясый, театр, соңгы, беренче, танылган, шагыйрь, атаклы

**5. Прослушайте и скажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Шагыйрь чыгыш ясый. Шагыйрь сәхнәдә чыгыш ясый.

2) Танылган җырчы җырлый. Танылган җырчы бик матур җырлый.

3) Мәктәп сәхнәсендә уйныйлар. Мәктәп сәхнәсендә соңгы әсәрне уйныйлар.

## 96–102 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите количество слогов в данных словах.**
Казаннан, Чаллыга, Чаллыдан, Казанга, өйдән, мәктәпкә

**2. Прослушайте и измените слова по образцу.**

О б р а з е ц : *Чаллыдан Казанга – Чаллыдан Казанга кадәр бик ерак.*

Алабугадан Чаллыга, Мамадыштан Казанга, Казаннан Уфага

**3. Прослушайте и укажите предложения, выражающие просьбу, разрешение.**

1) Казанга барам. Казанга барыйм әле. Казанга барасыңмы?
2) Мамадышка бар әле. Мамадышка барасыңмы? Мамадышка барыйм әле.
3) Минзәләгә барасыңмы? Минзәләгә барыгыз. Минзәләгә барырга мөмкинме?

**4. Прослушайте текст и перескажите.**

Казанда татар театрлары, курчак театры, цирк, зоопарк, зур китапханәләр бар. Мин Казанда йөрергә яратам. Җәй көне Казанга барырга уйлыйм.

**5. Прослушайте предложения и поставьте к ним вопросы.**

1) Без бүген театрга бардык.
2) «Авыл эте Акбай» спектаклен карадык.
3) Спектакль безгә бик ошады.
4) Артистлар яхшы уйнадылар.

**6. Прослушайте текст и перескажите, дополнив его.**

Казанда бик матур бина бар. Ул Кабан күле буенда урнашкан. Бу – Татар дәүләт Академия театры.

## Контроль һәм үзконтроль өчен үрнәк биремнәр

### Яңа уку елы башлана

**1. Переведи.**

Изучает татарский язык, рассказывает стихотворение, разговаривает по-татарски, русско-татарский словарь, городская библиотека, книги о животных, опоздал на урок, получил пятёрку.

**2. Дополни диалог.**

– … ?
– Мин 6 нчы сыйныфта укыйм.
– … ?
– Мин 15 нче мәктәптә укыйм.

**3. Как скажешь, что:**

– вы учитесь в 6 классе;
– у вас сегодня 6 уроков;
– уроки начинаются в половине 9-го;
– ты любишь читать книги о животных?

**4. Спроси у друга:**

– чья эта книга;
– сколько стоит эта книга;
– нужна ли ему эта книга;
– нет ли у них дома книги о Казани;
– есть ли у них татарско-русский словарь.

**5. Посоветуй другу:**

– беречь книги;
– записывать домашнее задание;
– найти по Интернету материал;
– выучить стихотворение;
– сходить в библиотеку;
– купить словарь;
– не опаздывать на урок.

**6. Как спросишь у Марата:**
- где его словарь;
- какие оценки он получил на этой неделе;
- записывает ли он домашнее задание?

**7. Дополни диалог.**
- ... ?
- Рәхим итегез.
- ... ?
- Әлбәттә, мөмкин. ... ?
- Романов Олег.
- ... ?
- 6 нчы сыйныфта.
- Адресың ничек?
- ... .
- Нинди китап кирәк?
- ... .

**8. Дополни диалог.**
- … ?
- Әйе, мин китапханәгә барам.
- ... ?
- Миңа Муса Җәлил турында китап кирәк.

## Мин – өйдә булышчы

**1. Переведи.**

Булыша, өй җыештыра, идән себерә, тузан сөртә, өстәл җыештыра, урын җыештыра, кибеткә бара, ипи алып кайта, эшчән, тырыш, ялкау, хезмәт ярата.

**2. Дополни диалог.**
- ... ?
- Әйе, мин өйдә булышам.
- Нәрсә эшлисең?
- ... .

**3. Как скажешь о том, что ты:**
- чистил картошку;
- покупал продукты;
- убирался в комнате?

**4. Как скажешь о том, что надо:**
- чистить картошку;
- купить продукты;
- убраться в комнате?

**5. Продолжи диалог.**
- Настя, әйдә бергә өстәл әзерлибез.
- Әйдә, мин риза. Миңа нәрсә эшләргә?
- ... .

**6. Как попросишь помочь тебе:**
- чистить картошку;
- купить продукты;
- убраться в комнате?

### Туган җирем – Татарстан

**1. Переведи.**

Туган ил, дәүләт, дәүләт символлары, туган җир, халык, милләт, башкала, инглиз теле, тел, рус, татар, русча.

**2. Дополни диалог.**
- Россия гербында нәрсә ясалган?
- ... .
- Татарстан гербында нәрсә ясалган?
- ... .
- Россия флагында нинди төсләр бар?
- ... .
- Татарстан флагында нинди төсләр бар?
- ... .

**3. Күп нокталар урынына сораулар куеп яз.**

– ... ?

– Без Татарстанда яшибез.

– ... ?

– Татарстанда татарлар, руслар, башкортлар һәм башка милләт кешеләре яши.

– ... ?

– Алар дус һәм тату яшиләр.

**4. Как скажешь о том, что:**

– любишь свою Родину;

– в вашем классе учатся русские, татары, чуваши?

**5. Дополни диалог.**

– Син нинди телләрдә сөйләшәсең?

– ... .

**6. Скажи о том, что:**

– Казань – большой красивый город;

– в Казани много музеев.

**7. Спроси у друга:**

– был ли он в казанском метро;

– сколько станций есть в метро.

**8. Предложи другу:**

– поехать на метро до Кремля;

– посмотреть Казанский Кремль.

**9. Дополни диалог.**

– … ?

– Казанда Татарстан Республикасы Милли музее, Габдулла Тукай музее, Максим Горький музее, Каюм Насыйри музее бар.

– Син нинди музейда булдың ?

– ... .

**10. Скажи о том, что:**

– ты был в Казани;
– ты был в музее М. Горького;
– тебе музей очень понравился;
– в музее много экспонатов.

**11. Спроси у друга:**

– какие музеи есть в Казани;
– был ли он в музее;
– был ли он в Казанском Кремле.

## Сәламәт тәндә – сәламәт акыл

**1. Переведи.**

Сәламәт, сәламәтлек, файдалы, авырый, авырта, спорт төре, спорт түгәрәге, юл йөрү кагыйдәләрен үтәргә, игътибарлы булырга.

**2. Дополни диалог.**

1) – Син нинди спорт төрләре яратасың?
– ... .

2) – ... ?
– Мин стадионга барам.
– Стадионда нишлисең?
– ... .

**3. Продолжи предложения.**

1) Мин җәй көне футбол уйныйм, ... .
2) Мин кыш көне чана шуам, ... .

**4. Позови друга:**

– кататься на лыжах, санках;
– играть в футбол, в волейбол, в бадминтон.

**5. Саша почему-то не играет в футбол. Узнай у него, почему он не играет. Предложи поиграть вместе.**

**6. Как скажешь о том, что ты хочешь стать:**
- футболистом;
- хоккеистом;
- борцом;
- пловцом;
- теннисистом?

**7. Продолжи предложения.**
1) Сәламәт булу өчен, ... .
2) Сәламәт булу өчен, ... .
3) Сәламәт булу өчен, ... .

**8. Скажи о том, что у тебя болит рука (зуб, нога, ухо).**

**9. Спроси у друга, болит ли у него рука (зуб, нога, ухо).**

**10. Спроси у друга:**
- нет ли у него температуры;
- выпил ли он лекарство.

**11. Посоветуй младшему брату:**
- быть внимательным на дороге;
- соблюдать правила дорожного движения.

# ЭЧТӘЛЕК

6 нчы сыйныфта «Татарстан Республикасы дәүләт (татар) теле» фәнен укыту өчен төзелгән «Татар теле» укыту-методик комплекты белән эшләү үзенчәлекләре ........ 3

Календарь-тематик план ........ 7

Ишетеп аңлау күнегүләре ........ 12

Контроль һәм үзконтроль өчен үрнәк биремнәр ........ 29

*Методическое пособие*

**Хайдарова** Роза Закиевна
**Ахметзянова** Гульназ Магсумзяновна
**Гиниятуллина** Лейсан Адиповна

Обучение татарскому языку
в образовательных организациях основного общего образования
с обучением на русском языке

6 класс

Пособие для учителей

Редакторы:
**Ильгизар Закиев,**
**Алсу Низамеева**

Компьютерная вёрстка
**Елены Шараповой**

Подписано в печать 10.08.2025.
Формат 170×205 1/4. Бумага офсетная.
Гарнитура «Arial». Тираж         экз. Заказ №

Издательство «Татармультфильм»
420066, г. Казань, пер. Односторонки Гривки, д. 32, помещ. 2

Отпечатано в полном соответствии с качеством
предоставленных материалов в типографии



«Татармультфильм»